КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 303

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 19 август, 379 нчы карары белән расланган Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 19 август, 379 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 13 май, 359 нчы; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче; 2016 ел, 11 июнь, 398 нче; 2018 ел, 21 май, 382 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 930 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче; 2023 ел, 22 март, 318 нче; 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 пунктта:

бишенче абзацта «торак пунктлардан, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләреннән читтә һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрдән читтә» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«торак пунктлар, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен төзү.»;

17 пунктның өченче абзацында «Идел-Каспий балыкчылык хуҗалыгы бассейны өчен балык тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 453 номерлы» сүзләрен «Идел-Каспий балык хуҗалыгы бассейны өчен балык тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 13 октябрендәге 695 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктның унтугызынчы, егерме икенче, егерме өченче, егерме җиденче, утыз алтынчы һәм утыз җиденче абзацларын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин